| СОВЕТ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|
| **РЕШЕНИЕ**<br>10 ноября 2015 года | Зеленодольск шәһәре | **КАРАР**<br>№ 24 |

Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 03 июлендәге 333 номерлы «2009 елга К2 кеременә бердәм салым кулланыла торган һәм база керемнәре коэффициентын корректорлый торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләрен билгеләү турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында (Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 20 октябрендәге 382 номерлы, 2009 елның 15 декабрендәге 495 номерлы, 2010 елның 13 ноябрендәге 11 номерлы, 2012 елның 21 ноябрендәге 205 номерлы, 2013 елның 06 маендагы 261 номерлы,2013 елның 14 ноябрендәге 325 номерлы, 2014 елның 30 июнендәге 408 номерлы, 2014 елның 26 ноябрендәге 464 карарлары белән кертелгән, үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.В.Точилкинның Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 03 июлендәге 333 номерлы номерлы «2009 елга К2 кеременә бердәм салым кулланыла торган һәм база керемнәре коэффициентын корректорлый торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләрен билгеләү турында”гы (Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 20 октябрендәге 382 номерлы, 2009 елның 15 декабрендәге 495 номерлы, 2010 елның 13 ноябрендәге 11 номерлы, 2012 елның 21 ноябрендәге 205 номерлы, 2013 елның 06 маендагы 261 номерлы, 2013 елның 14 ноябрендәге 325 номерлы, 2014 елның 30 июнендәге 408 номерлы, 2014 елның 26 ноябрендәге 464 карарлары белән кертелгән, үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматын тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Салым кодексының 26.3 бүлегенә, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Советы 2008 елның 03 июлендәге 333 номерлы «2009 елга К2 кеременә бердәм салым кулланыла торган һәм база керемнәре коэффициентын корректорлый торган эшмәкәрлек эшчәнлеге төрләрен билгеләү турында”гы карарына (Зеленодольск

муниципаль районы Советы 2008 елның 20 октябрендәге 382 номерлы, 2009 елның 15 декабрендәге 495 номерлы, 2010 елның 13 ноябрендәге 11 номерлы, 2012 елның 21 ноябрендәге 205 номерлы, 2013 елның 06 маендагы 261 номерлы, 2013 елның 14 ноябрендәге 325 номерлы, 2014 елның 30 июнендәге 408 номерлы, 2014 елның 26 ноябрендәге 464 карарлары белән кертелгән, үзгәрешләр белән) (алга таба – Карар) түбәндәге үзгәрешне кертергә:
Карарга 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Зеленодольск муниципаль районы
Башкарма комитетының
2008 елның 03 июлендәге
333 номерлы карарына
2 кушымта

Зеленодольск муниципаль районы территориясендә 2016 елдан эшчәнлекнең аерым төрләрен гамәлгә ашыручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен берләштерелгән керемгә бердәм салым суммасын исәпләү өчен К2 база керемнәре коэффициентын корректорлый торган күрсәткечләр таблицасы

| № п/п | Эшчәнлек төрләре исеме | К2 коэффициентының күрсәткечләре | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Зеленодольск шәһәре | Васильево ш.т. п., Карамалы Тау ш.т.п., Осиново авыл җирлеге, Октябрь авыл җирлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге | калган авыл җирлекләре * |
| 1. | Аерым көнкүреш хезмәт күрсәтүләр, аларның төркемнәре, ярдәмче төркемнәре хезмәтләре һәм (яки) аерым көнкүреш хезмәт күрсәтүләрдән тыш: | 0,5 | 0,3 | 0,2 |
| 1.1 | Мунча һәм душ хезмәте күрсәтү | | | |
| 1.1.1 | 40 урынга кадәр мунча һәм душ хезмәтләре күрсәтү һәм мунчаларда һәм душ бүлмәләрендә күрсәтелә торган башка хезмәтләр | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 1.1.2 | 40 урыннан артык мунча һәм душ хезмәтләре күрсәтү | 0,15 | 0,15 | 0,15 |
| 1.2 | Чәчтараш хезмәтләре күрсәтү | 0,7 | 0,4 | 0,3 |
| 2. | Ветеринар хезмәтләрен күрсәтү | 0,6 | 0,4 | 0,3 |
| 3. | Автомототранспорт чараларын ремонтлау, техник хезмәт күрсәтү һәм юу буенча хезмәт күрсәтү | | | |
| 3.1 | Автомототранспорт чараларын ремонтлау һәм техник хезмәт күрсәтү | 0,9 | 0,6 | 0,4 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3.2 | Автомототранспорт чараларын юу | 1,0 | 0,7 | 0,4 |
| 4. | Автомототранспорт чараларын кую урыннарын вакытлыча тоту (файдалану) өчен, шулай ук түләүле стоянкаларда автомототранспорт чараларын саклау буенча хезмәт күрсәтү (штраф автостоянкаларыннан тыш) | 0,6 | 0,5 | 0,4 |
| 5. | Хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән 20дән дә артмаган транспорт чарасы милек хокукында яисә башка хокукта (файдалану, биләү һәм (яки) белән эш итү) булган оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр тарафыннан пассажирлар һәм йөк ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 5.1 | Йөк ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | 0,65 | 0,5 | 0,3 |
| 5.2 | Пассажирлар ташу буенча автотранспорт хезмәтләре күрсәтү | | | |
| 5.2.1 | 18 урынга кадәр (шул исәптән) аеруча аз сыйдырышлы автобуслар белән | 0,25 | 0,25 | 0,2 |
| 5.2.2 | 19-30 урынга кадәр (шул исәптән) аз сыйдырышлы автобуслар белән | 0,15 | 0,15 | 0,1 |
| 5.2.3 | 30 урыннан артык сыйдырышлы автобуслар белән | 0,1 | 0,1 | 0,07 |
| 5.2.4 | җиңел таксомоторлар / шәһәр һәм шәһәр яны элемтәсендә | 1,0 | 0,7 | 0,4 |
| 6. | Сәүдә залының мәйданы һәр сәүдә оешмасы объекты буенча 150 кв. метрдан артмаган кибетләр һәм павильоннар аша сатыла торган ваклап сату | 0,75 | 0,6 | 0,4 |
| 7. | Стационар сәүдә челтәре объектлары аша, сәүдә заллары булмаган, шулай ук стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша сатыла торган ваклап сату | | | |
| 7.1 | Стационар сәүдә челтәре объектлары аша, сәүдә заллары булмаган, шулай ук сәүдә урыны мәйданы 5 квадрат метрдан артмаган стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша сатыла торган ваклап сату | 0,5 | 0,4 | 0,2 |
| 7.2 | Стационар сәүдә челтәре объектлары аша, сәүдә заллары булмаган, шулай ук сәүдә урыны мәйданы 5 квадрат метрдан артып киткән стационар булмаган сәүдә челтәре объектлары аша сатыла торган ваклап сату | 0,6 | 0,4 | 0,2 |
| 7.3 | Китереп  һәм ваклап сату | 0,4 | 0,35 | 0,2 |
| 7.4 | Сәүдә автоматларыннан файдаланып товарлар сату | 1,0 | 1,0 | 1,0 |
| 8. | Халыкка хезмәт күрсәтү залының мәйданы 150 квадрат метрдан артмаган җәмәгать туклануын оештыру  объектлары аша гамәлгә ашырыла торган җәмәгать туклануы | 0,6 | 0,45 | 0,2 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | хезмәтләре күрсәтү, җәмәгать туклануын оештыруның һәр объекты буенча җәмәгать туклануын оештырудан тыш: | | | |
| 8.1 | Предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар территорияләрендә ведомство ашханәләре тарафыннан җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша гамәлгә ашырыла торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | 0,45 | 0,35 | 0,2 |
| 8.2 | подакцизм товарлар сатмыйча гына җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша гамәлгә ашырыла торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | 0,35 | 0,25 | 0,2 |
| 8.3 | Бюджеттан финанслана торган уку йортларына хезмәт күрсәтүче оешмалар тарафыннан җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | 0,3 | 0,2 | 0,2 |
| 9. | Килүчеләргә хезмәт күрсәтү залы булмаган җәмәгать туклануын оештыру объектлары аша гамәлгә ашырыла торган җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү | 0,6 | 0,4 | 0,2 |
| 10. | Реклама конструкцияләрен кулланып тышкы реклама тарату | 0,2 | 0,2 | 0,2 |
| 11. | Транспорт чараларының тышкы һәм эчке өслекләрен файдаланып реклама урнаштыру | 0,2 | 0,2 | 0,2 |
| 12. | Әлеге хезмәтләр күрсәтүнең һәр объектында вакытлыча урнаштыру һәм яшәү өчен биналарның гомуми мәйданы 500 квадрат метрдан да ким булмаган гомуми мәйданы булмаган әлеге хезмәтләрне кулланучы оешмалар һәм эшмәкәрләр тарафыннан вакытлыча урнаштыру һәм яшәү буенча хезмәтләр күрсәтү | 0,55 | 0,4 | 0,3 |
| 13. | Стационар сәүдә челтәре объектларында, сәүдә заллары, стационар булмаган сәүдә челтәре объектларында урнашкан сәүдә урыннарын, шулай ук килүчеләргә хезмәт күрсәтү заллары булмаган җәмәгать туклануын оештыру объектларын вакытлыча куллануга һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү | | | |
| 13.1 | Стационар сәүдә челтәре объектларында, сәүдә заллары, стационар булмаган сәүдә челтәре объектларында урнашкан сәүдә урыннарын, шулай ук килүчеләргә хезмәт күрсәтү заллары булмаган җәмәгать туклануы объектларын, аларның һәркайсының мәйданы 5 квадрат метрдан артмаса, вакытлыча | 0,5 | 0,4 | 0,3 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | кулланугa һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү | | | |
| 13.2 | Стационар сәүдә челтәре объектларында, сәүдә заллары, стационар булмаган сәүдә челтәре объектларында урнашкан сәүдә урыннарын, шулай ук кулланучыларга хезмәт күрсәтү заллары булмаган җәмәгать туклануы объектларын, аларның һәркайсының мәйданы 5 квадрат метрдан артса, вакытлыча кулланугa һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү | 0,35 | 0,3 | 0,25 |
| 14. | Стационар һәм стационар булмаган сәүдә челтәре объектларын, шулай ук җәмәгать туклануын оештыру объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен вакытлыча кулланугa һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү | | | |
| 14.1 | Стационар һәм стационар булмаган сәүдә челтәре объектларын, шулай ук җәмәгать туклануын оештыру объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен, әгәр җир участогы мәйданы 10 квадрат метрдан артмаса, вакытлыча кулланугa һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү, | 0,5 | 0,4 | 0,15 |
| 14.2 | Стационар һәм стационар булмаган сәүдә челтәре объектларын, шулай ук җәмәгать туклануын оештыру объектларын урнаштыру өчен җир кишәрлекләрен, әгәр җир участогы мәйданы 10 квадрат метрдан артса, вакытлыча кулланугa һәм (яки) файдалануга тапшыру буенча хезмәт күрсәтү, | 0,5 | 0,4 | 0,1 |

* Зеленодольск муниципаль районының калган авыл җирлекләре: Әйшә, Акъегет, Бишнә, Олы Ачасыр, Олы Ключи, Олы Карагужа, Олы Шырдан, Олы Җәке, Күгәй, Күгеш, Мамадыш-Әкил, Мулла Иле, Түбән Урысбага, Новопольский, Норлат, Раифа, Рус Әҗиле, Өтәшкә авыл җирлекләре.»

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көннән бер айдан да соңга калмыйча, үз көченә керә.

3. Әлеге карарны 2015 елның 1 декабренә кадәр «Зеленодольская правда» һәм «Яшел Үзән» газеталарында бастырып чыгарырга, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru) Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмати сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы Башлыгы,**
**Совет рәисе** **А. В. Тыгин**